Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«23» апрель 2019 ел № 45

Территорияне межалау проектын әзерләү
турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә 2019 елның 4 апрелендәге 2438 номерлы үзгәрешләр кертү буенча Комиссия бәяләмәсе нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Шакиров Ринат Таһир улына үз акчалары хисабына Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Урсала мик., Гомәр Бәширов ур., 2 йорт адресы буенча урнашкан, кадастор номеры 16:45:020157: 180 булган җир кишәрлегенә карата кызыл линияләрне үзгәртү өлешендә территорияне межалау проектын эшләүгә керешергә тәкъдим итәргә.

2. «Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе нигезендә әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Мөхәммәтҗанов А.А. ка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев